# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Кәүҗияк торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

**2023 елның 17 ноябре** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Кәүҗияк торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк Кәүҗияк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшькә җиткәннәр), көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, һәм вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылардан кала, 2024 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Кәүҗияк торак пункты территориясендәге юл кырыенда үлән чабу;

2) Сарман муниципаль районы, Кәүҗияк авылы, Совет урамы, 14в йорт адресы буенча Кәүҗияк торак пунктында һәйкәлне ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу) ;

3) янгынга каршы җиһазлар сатып алу: янгынга каршы рюкзак, Кәүҗияк торак пунктында су алу өчен янгын колонкасы;

4) Кәүҗияк торак пунктында Җәлил урамындагы тыкрыктагы вак таш япмаларын ремонтлау( таш ташу);

5) мәгълүмат щитларын һәм күрсәткечләрен, үзгәрешле мәгълүмат билгеләрен (Чик буе күрсәткечләрен торгызу)хезмәтләндерү һәм торгызу.

3. Җыен нәтиҗәләрен Кәүҗияк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгы Ф. Ә. Хөснетдинов